**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Би Күле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

«04» апрель 2024 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлеге Би Күле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

«Сез гражданнар җыенында элек расланган мәсьәләләргә үзгәрешләр кертүгә ризамы;

- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 20.10.2023 ел, № 3 карары
- Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылында гражданнар җыены карары 20.10.2023 № 4,

аны түбәндәге редакциядә раслап:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Би Күле авыл җирлегенең Би Күле авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, балачак инвалидларыннан, 1 гр инвалидлардан тыш, 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын салу, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү;

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары составына кермәгән җәяүлеләр күперләрен ремонтлау;

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А.М.Шакирова

Би Күле авыл җирлеге башлыгы А.М.Шакирова